СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«СТАРОКУВАКСКОЕ
СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»
ЛЕНИНОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ИСКЕ КУАК
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ

КАРАР

2023 елның 14 марты Иске Куак № 7

«Иске Куак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2021 елның 26 мартындагы 7 номерлы карары белән расланган Иске Куак авыл җирлегенең депутатына, җирле үзидарәнең сайлап куелган органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затына карата үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре шулай ук, әгәр бу бозып күрсәтелгән мәгълүматлар мөһим булмаса, хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яки тулы булмаган мәгълүматлар биргән өчен җаваплылык чараларын куллану турында карар кабул итү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 31 декабрендәге 109-ТРЗ номерлы ( 26.01.2023 ел ред.) Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» «Иске Куак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. «Иске Куак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2021 елның 26 мартындагы 7 номерлы карары белән расланган Иске Куак авыл җирлегенең депутатына, җирле үзидарәнең сайлап куелган органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затына карата үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре шулай ук, әгәр бу бозып күрсәтелгән мәгълүматлар мөһим булмаса, хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яки тулы булмаган мәгълүматлар биргән өчен җаваплылык чараларын куллану турында карар кабул итү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктның 2 абзацында, 4 пунктында, 5 пунктның 3 абзацында, 6 пунктның 1 абзацында, 7 пунктның 1,3 абзацларында «Президентны» сүзен «Башлыгын - Рәисен» сүзләренә алмаштырырга;

11 пунктның 1 абзацында «Президентка» сүзен «Башлыгына - Рәисенә» сүзләренә алмаштырырга.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Иске Куак авылы, Заварыкин ур., 36, Яшел ур., 7 адресы буенча урнашкан мәгълүмати стендларда игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (leninogorsk.tatar.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплыгымда калдырам.

Лениногорск муниципаль районы
«Иске Куак авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Совет рәисе — И.Н.Сушкова